**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14,E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ ПР-219 18.10.2024 № _____

Актаныш муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт турында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Актаныш муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, Актаныш муниципаль районы башкарма комитетына Актаныш муниципаль районы җирлекләре башкарма комитетларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы килешүне гамәлгә ашыру максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җаваплы итеп Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген билгеләргә.
2. Актаныш муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтнең вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында рәсми рәвештә игълан итәргә.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Расланган
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
________ ____ №___ белән

Актаныш муниципаль районы территориясендә җирләү мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе

Әлеге тәртип «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

1 бүлек Гомуми нигезләмәләр

1.1. Актаныш муниципаль районы территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт буларак Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - махсуслаштырылган хезмәт) чыгыш ясый. Махсуслаштырылган хезмәт җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеген түләүсез нигездә күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

Махсуслаштырылган хезмәт үз эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 01 апрелендәге 64/0 номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасында зиратларны төзекләндерү һәм карап тоту, күмү эшен оештыру буенча методик тәкъдимнәр, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, Актаныш муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, әлеге Тәртипкә таянып эш итә.

1.2. Махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе Актаныш муниципаль районы муниципаль акты белән раслана.

1.3. Махсуслаштырылган хезмәт җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеген күрсәтү кысаларында эшләр башкаруга физик яисә юридик затлар белән контрактлар (килешүләр) төзи.

2 бүлек Махсуслаштырылган хезмәтнең төп функцияләре һәм бурычлары

2.1. Җирләү эше өлкәсендә вәкаләтләрнең бер өлешен район дәрәҗәсенә тапшыру турында килешүләр төзелгән җирлекләрнең җәмәгать зиратларында махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең түбәндәге исемлеге түләүсез нигездә күрсәтелә:

1) җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;
2) табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү;
3) вафат булган кешенең гәүдәсен (мәетне) зиратка илтү;
4) җирләү.

2.2. Җәмәгате, якын туганнары, башка туганнары, яки мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яисә аларны күмү мөмкин булмаганда, шулай ук җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда, өйдә, урамда яисә башка урында үлгән кешене күмгәндә, аның шәхесен эчке эшләр органнары билгеләгәннән соң, үлем сәбәпләрен билгеләгән вакыттан алып өч тәүлек эчендә махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан гамәлгә ашырыла, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса.

2.3. Шәхесләре Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вакытта эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнмәгән вафат булганнарны җирләү, әлеге органнарның ризалыгы белән, мондый очраклар өчен билгеләнгән җәмәгать зиратларында җирләү юлы белән махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан башкарыла.

2.4. Бу Тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән, вафат булганнарны җирләгәндә махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр үз эченә ала:

1) җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү;

2) вафат булган кешене кәфенләү;

3) табут бирү;

4) вафат булган кешене зиратка илтү;

5) җирләү.

2.5. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтү махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда башкарыла.

## 3 бүлек Махсуслаштырылган хезмәт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга таләпләр

3.1. Махсуслаштырылган хезмәт Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм җирләү өлкәсендә муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәргә тиеш, шул исәптән:

- түләүсез нигездә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәтләр күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре;

- җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә керүче хезмәтләр күрсәтү сыйфатына карата таләпләр.

3.2. Кирәкле чаралар булмауга яисә башка сәбәпләр аркасында махсушлаштырылган хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтүдән баш тарту рөхсәт ителми.

3.3. Махсуслаштырылган хезмәт түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) вафат булган кешенең ихтыяр белдерүен гамәлгә ашыручы затларга, шулай ук вафат булучының җәмәгате, якын туганнарының, башка туганнарының, законлы вәкилләрнең, үлгән кешене күмүне гамәлгә ашыру бурычларын үз өстенә алган башка затларның күмүне гамәлгә ашыруда каршылык күрсәтергә;

2) махсуслаштырылган хезмәттән ритуаль хезмәтләр, шул исәптән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә керә торган хезмәтләрне түләүле нигездә сатып алуны мәҗбүр итәргә (ирексезләп кушарга).

## 4 бүлек Махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибенә төп таләпләр

4.1. Махсуслаштырылган хезмәт күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерә, гореф-гадәтләр һәм традицияләр нигезендә күмү датасын һәм вакытын, шулай ук диненә туры китереп билгели.

Документларны рәсмиләштерү нәтиҗәләре буенча махсуслаштырылган хезмәт әлеге Тәртипнең 2 бүлегенә ярашлы рәвештә җирләү буенча хезмәт күрсәтә.

4.2. Махсуслаштырылган хезмәт консультатив ярдәм күрсәтә:

җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеген күрсәтү тәртибе буенча;

зиратларның эш кагыйдәләре буенча;

җирләүгә социаль пособие бирү тәртибе һәм күләме буенча һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә җирләү һәм күмү эше өлкәсендә гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтү тәртибе буенча.

4.3. Махсуслаштырылган хезмәт бинасында күзәтү өчен мөмкин булган урында түбәндәге мәҗбүри мәгълүмат булырга тиеш:

1) «Куллanучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

2) «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон;

3) «Вафат булганнарны җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүгә гражданнарның хокукларын гарантияләү турында» Россия Федерациясе Президентының 1996 елның 29 июнендәге 1001 номерлы указы;

4) җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге.

## 5 бүлек Махсуслаштырылган хезмәтнең җаваплылыгы

Җирләү һәм күмү эше өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен махсуслаштырылган хезмәт гамәлдәге законнар нигезендә җаваплы.